Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР № LIV-3

Балык Бистәсе штп.

2024 елның 28 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 1 декабрендәге XV-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы», «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 1 декабрендәге XV-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 4.4.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.3. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары, планнан тыш тикшерүләр фәкать түбәндәге нигезләр буенча гына үткәрелә:

а) прокуратура органнары белән килештерү шарты белән:

- гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры зыян китерү куркынычы булганда, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә авыр зыян китерү фактлары буенча;
- ил оборонасына һәм дәүләт иминлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда, ил оборонасына һәм дәүләт иминлегенә зыян китерү фактлары буенча;
- табигый һәм (яисә) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда, табигый һәм (яисә) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу фактлары буенча;
- мәҗбүри таләпләрне бозуның хәвефлек индикаторлары ачыкланганда;

- 2023 елның 1 мартына кадәр дип бирелгән гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә, ил оборонасына һәм дәүләт иминлегенә турыдан-туры зыян китерүгә, табигый һәм (яисә) техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерә торган хокук бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрү турында күрсәтмәне үтәү срогы тәмамлануга бәйле рәвештә планнан тыш күчмә тикшерү, планнан тыш инспекция визиты үткәрергә кирәк булган очракта. Планнан тыш күчмә тикшерү һәм планнан тыш инспекция визиты бары тик документлар, контроль (күзәтчелек) органы карамагында булган башка мәгълүмат нигезендә күрсәтмәнең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаган очракларда гына үткәрелә;

- контроль-касса техникасын куллану турында Россия Федерациясе законнары үтәлешенә, шул исәптән оешмаларда һәм шәхси эшмәкәрләрдә керемнәрне исәпкә алуның тулылыгына федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Федераль салым хезмәте җитәкчесе, җитәкче урынбасары карары буенча («Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»Федераль законның 75 маддәсендәге 7 өлешендә билгеләнгән очраклардан гайре);

- хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча Федераль хезмәт җитәкчесе (җитәкче урынбасары) яисә аның территориаль органнары карары буенча хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кысаларында, эш бирүчеләрнең хезмәт хокукларын күпләп (исемлек буенча уртача санның 10 проценттан артыграгы яисә 10 кешедән артыграгы) бозулары турында мәгълүматлар булган мөрәҗәгатьләр (мәгълүмат) хезмәткәрләреннән бер айдан артык хезмәт хакын тулысынча яисә өлешчә түләмәүгә бәйле булган очракта;

- операторларга карата шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт җитәкчесе, җитәкче урынбасары карары буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәхси мәгълүматлар булган мәгълүмат базасын (яисә аларның өлешләрен) тарату (бирү) факты билгеләнгән очракта;

- 2023 елның 1 мартыннан соң бирелгән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуны бетерү турында күрсәтмәне үтәү срогы тәмамлангач, әлеге пунктның "б" пунктчасының уникенче абзацында каралган очрактан гайре;

- юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 8 маддәсендәге 2 өлешендә күрсәтелгән эшкуарлык эшчәнлеге төрләрен гамәлгә ашыру фактлары турында мәгълүматлар кергәндә, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»Федераль законның 8 маддәсендәге 1 өлешендә каралган эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамә тапшырмыйча;

б) прокуратура органнары белән килештермичә:

- Россия Федерациясе Президенты кушуы (йөкләмәсе) буенча;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең әлеге карар үз көченә кергәннән соң кабул ителгән йөкләмәсе буенча;

- әлеге карар үз көченә кергәннән соң кабул ителгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары - Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппараты җитәкчесе белән килештерелгән Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисе урынбасарының йөкләмәсе буенча;

- прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешен, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешен күзәтү кысаларында прокурор таләбе буенча;

- тикшерүләр программасында күрсәтелгән вакыйга килеп чыкканда (дәүләт төзелеш күзәтчелеген, федераль дәүләт экология контролен (күзәтчелеген), мәдәни мирас объектларының торышына, аларны карап тотуга, саклап калуга, алардан файдалануга, аларны популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына дәүләт контролен (күзәтчелеген), дарулар әйләнеше өлкәсендә федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда);

- контрольдә тотылучы зат лицензия, аккредитация яисә рөхсәт бирү характерындагы башка документның элек туктатып торылган гамәлдә булуын алу яисә яңарту максатларында контроль (күзәтчелек) органы күрсәтмәсенең яисә башка карарының үтәлеше турында документлар һәм (яисә) мәгълүматлар тапшырганда;

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»Федераль законның 10 маддәсендәге 2 өлешенең 1.1 пунктында билгеләнгән планнан тыш тикшерүләр, үткәрү өчен нигезләр;

- гражданнарның үзләренең бозылган хокукларын яклауга (торгызуга) бәйле рәвештә шикаяте (шикаятьләре) кергән очракта күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга региональ дәүләт лицензия контроле һәм региональ дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) кысаларында;

- контроль (күзәтчелек) органына сорау алучыдан, сорау алу органыннан, тикшерүчедән, тикшерү органы җитәкчесеннән йә оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы органнан җинаять турында тикшерү үткәргәндә яисә оператив-эзләү чараларын үткәргәндә аларны җитештерү өчен җинаять эше буенча матди дәлилләр булып тормаган продукцияне (товарларны), җайланмаларны (чараларны) тартып алу турында материаллар кергәндә планнан тыш документар тикшерүләр;

- контроль (күзәтчелек) органына административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле органнардан, вазыйфаи затлардан, әйләнеше дәүләт контроле (күзәтчелеге)предметына кертелгән мәҗбүри таләпләрне бозып гамәлгә ашырыла торган кылган эш кораллары яисә административ хокук бозу предметлары булган әйберләрне тартып алу турындагы материаллар кергәндә планнан тыш документар тикшерүләр;

- әлеге пунктчаның алтынчы абзацы нигезендә уздырылган планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасы нәтиҗәләре буенча 2023 елның 1 мартыннан соң бирелгән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәү срогы тәмамлангач;

- Федераль иминлек хезмәте органнарыннан ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү

турында яисә зарар (зыян) салу куркынычы турында мәгълүматлар булган транспорт иминлеге өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу ихтималы турында мәгълүмат алынганда. Күрсәтелгән очракта планнан тыш күчмә тикшерү һәм планнан тыш рейд тикшерүе бу хакта тикшерү объекты урнашкан урындагы прокуратура органына хәбәр итеп (тиешле мәгълүматларны алганнан соң 24 сәгать эчендә) үткәрелә;

в) «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» Федераль законның 32 маддәсендәге 4.2 пунктының 2, 3, 5 һәм 6 пунктчаларында билгеләнгән нигезләр буенча коммерциягә карамаган оешмаларга карата прокуратура органнарына хәбәр итү белән, шулай ук «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында»Федераль законның 25 маддәсендәге 5 пунктының өченче абзацында билгеләнгән нигез буенча дини оешмаларны.»;

1.2) 4.6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.3. Планнан тыш күчмә (урынга барып) тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, түбәндәге очраклардан гайре:

1) контрольдә тотылучы конкрет затларга карата контроль (күзәтчелек) чаралар уздыру турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе;

2) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешен, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешен күзәтчелек итү кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрү турында прокурор таләбе;

3) әлеге Федераль законның 95 маддәсендәге 1 өлешендә билгеләнгән очракларда контроль (күзәтчелек) органының мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуны бетерү турындагы карарын үтәү срогы тәмамлану;

4) контроль төре турындагы Федераль законда контроль (күзәтчелек) чараларының тикшерүләр программасы нигезендә уздырылуы билгеләнгән булса, тикшерүләр программасында күрсәтелгән вакыйганың башлануы (җитүе);

5) контрольдә тотылучы заттан контроль (күзәтчелек) органына рөхсәт режимнары кысаларында лицензияләү, аккредитацияләү, сертификацияләү, реестрга кертү, аттестацияләү, экспертиза узу һәм вакыты чикләнмәгән рөхсәтләр рәвешләрендә гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне (компетентлыкны) вакытлыча раслау процедуралары кысаларында ачыкланган бозуларны бетерү турында мәгълүмат алу тиешле рөхсәтләрнең гамәлдә булу характеры;

6) әгәр планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү өчен нигез булып закон белән саклана торган кыйммәтләргә (хәзинәләргә) зарар (зыян) китерү хәвефлеге турындагы мәгълүматлар торса;

7) Федераль иминлек хезмәте органнарыннан транспорт иминлеге өлкәсендә ил оборонасы һәм дәүләт иминлеге өлкәсендә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар салу, зыян китерү турында яисә зарар (зыян) китерү хәвефлеге турында мәгълүматлар булган мәҗбүри таләпләрне бозу ихтималы турында мәгълүмат алу.»;

1.3) 4.6.10 пунктында «хокуклы» сүзен «мөмкин»сүзенә алмаштырырга;

1.4) 4.7.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге д) пунктчасын өстәргә:

«д) инструменталь тикшерү»;

1.5) 4.7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7.3. Планнан тыш инспекция визиты прокуратура органнары белән килешү буенча гына уздырылырга мөмкин, түбәндәге очраклардан тыш:

1) контрольдә тотылучы конкрет затларга карата контроль (күзәтчелек) чаралар уздыру турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе;

2) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешен, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең үтәлешен күзәтчелек итү кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрү турында прокурор таләбе;

3) әлеге Федераль законның 95 маддәсендәге 1 өлешендә билгеләнгән очракларда контроль (күзәтчелек) органының мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуны бетерү турындагы карарын үтәү срогы тәмамлану;

4) контроль төре турындагы Федераль законда контроль (күзәтчелек) чараларының тикшерүләр программасы нигезендә уздырылуы билгеләнгән булса, тикшерүләр программасында күрсәтелгән вакыйганың башлануы (җитүе);

5) контрольдә тотылучы заттан контроль (күзәтчелек) органына рөхсәт режимнары кысаларында лицензияләү, аккредитацияләү, сертификацияләү, реестрга кертү, аттестацияләү, экспертиза узу һәм вакыты чикләнмәгән рөхсәтләр рәвешләрендә гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне (компетентлыкны) вакытлыча раслау процедуралары кысаларында ачыкланган бозуларны бетерү турында мәгълүмат алу тиешле рөхсәтләрнең гамәлдә булу характеры;

6) әгәр планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү өчен нигез булып закон белән саклана торган кыйммәтләргә (хәзинәләргә) зарар (зыян) китерү хәвефлеге турындагы мәгълүматлар торса;.»;

1.6) 4.8.2 пунктында:

1.6.1) «планнан тыш контроль чарасын үткәрү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6.2) 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 маддәсе нигезендә планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында карар;».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов